СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №87 (7260) | 20 июль, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## „Уңыш-91“ пресс-группасы хәбәр итә

Урып-җыю темп ала. 19 июльгә районда игеннәр 12262 гектарда урылды, бу—барлык мәйданның 23 проценты дигән сүз. Шуның 4791 гектары—борчак. Бүгенге көнгә бу культура барлык мәйданның 69 проценты күләмендә теземнәргә салынды. «Восход», «Россия», «Знамя Октября», «Татарстан» колхозлары аны уруны тулысынча төгәлләделәр, ә татарстанлылар исә суктыруны да тәмамладылар инде.

Районда уҗым культуралары өчен җир хәзерләү дәвам итә. Ул 7938 гектарда әзерләнде.

## Борчак урып-җыю тәмамланды

«Татарстан» колхозыннан шатлыклы хәбәр алынды. Хуҗалыкта 200 гектар мәйданда борчак җыю тәмамланды. Һава торышының яңгырлы торуына карамастан, механизаторлар көннең һәр аяз минутын нәтиҗәле эшкә файдаландылар.

Менә алар—кыр батырлары: комбайнчылардан Илдар Гайнуллин, Вәгыйзь Абдрахманов, Габбас Әсәдуллин, Радик Минапов, шоферлар Фаикъ Йосыпов, Рафик Хуҗиәхмәтов, Фәрит Галиуллин.

Техниканы алдан ышанычлы төзәтеп, эшләрен ял сәгатьләре белән исәпләшмичә, җиң сызганып башкарулары егетләргә районда беренчеләрдән булып борчакны суктырып бетерергә мөмкинлек бирде.

Эш комплекслы алып барыла. Кырда Сөләйман Әһлиуллин, Фәрит Манәпов тракторлары борчагы суктырылган саламны басу кырыена чыгаралар.

Ындыр табагында да кызу эш башланды. Анда эшләүче машинистлар Илһам Хафизуллин, Фоат Нотфуллин, Замир Дәүләтшин ашлык киптерү һәм эшкәртү машина һәм механизмнарын ышанычлы итеп көйләп-майлап куйганнар иде. Хәзер алар беренче ашлыкны кабул итеп, тиз арада борчакны чистартып, киптерүдә эшлиләр.

Шул ук вакытта уҗым арышының да 120 гектары суктырылды инде. Бүгенге көндә бөтен көч шуңа юнәлтелгән.

Р. ШӘЙХУЛЛИНА.



Валерий Яковлев үз теләге белән туган авылында эшкә калды. Кышкы чорда ул «Восход» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасында мөгезле эре терлекләр карый, алардан әйбәт кенә артым алуга ирешә.

Җәен, игеннәр өлгергәч исә Валерийны кыр корабы янында күрергә була. Хәзер ул үзенең СК-5 комбайны белән арыш ура. Билгеләнгән норманы үтәп барырга тырыша.

Әйе, авыл кешесе өчен һәрбер чор да җаваплы, киеренке .Шуңа ул бөтен энергиясен, тырышлыгын куя, эшнең җиңелен һәм авырын сайлап йөрми. Тәҗрибә үзеннән-үзе килми бит. Моның өчен нәкъ Валерий шикелле яшьтән үк хезмәтне яратырга өйрәнергә кирәк.

Рәсемдә: В. Яковлев.

## Беренче кыр батырлары

Урып-җыю үзенең беренче батырларын атый.

«Алга» колхозы комбайнчылары Илгиз Абдуллович РӘХИМОВ һәм Фаикъ Фатыйхович ФӘТТАХОВ «Нива» комбайны белән 1097, 1080 шәр центнер уҗым бодае суктырдылар. Фәрит Галимҗанович ШӘРӘКОВ исә аны 1389 центнерга җиткерде.

XXI партсъезд исемендәге колхоз механизаторлары Солтан Кәлимуллович АЛИЕВ арышны СК-5 комбайны белән теземнәргә салуда көнлек нормасын 250 шәр процентка үти.

«Комбайн» колхозы комбайнчысы Әсгать Баһаветдинович ӘХМӘТОВ борчак суктыруда көнлек нормасын 211 процентка үти. Аның исәбендә бүген 510 центнер суктырылган борчак исәпләнә.

«Үрнәк» колхозы механизаторы Фәнил Әсгатович КӘЛИМУЛЛИН исәбендә дә 100 гектар теземнәргә салынган игеннәр исәпләнә.

Игенчеләр! Урак батырларына тигезләнегез!

## Арендачылар эштә

Бу аренда звеносы дүртенче ел эшли инде. Алар карамагында 783 гектар җир исәпләнә, 11 кешедән торган звено анда бөртекле культуралар һәм шикәр чөгендере игә. Быел звенога Илһам Гәрәевич Хафизов җитәкчелек итә. Узган ел әлеге звено әйбәт кенә хезмәт куйды, аерым культуралар буенча 39—40 ар центнер уңыш алуга иреште, тулаем уңыш гектарыннан 26,4 центнер тәшкил итте.

Егетләрнең планнары быел да зурдан иде. Хәзер арендачылар уҗым культураларын җыюда эшлиләр.

И. ХӘНИЕВ.
«40 лет Победы» колхозы.

## Тәүге олаулар килде

17 июль көнне Норлат-Октябрь элеваторы агымдагы елның уңышын кабул итә башлады. Тәүге олаулар «1 нче Май», «Ленинский путь», «Үрнәк», «40 лет Победы», «Знамя Октября» колхозларыннан килделәр. Беренче көнне элеватор 136 тонна икмәк кабул итте, ул нигездә уҗым арышы.

Ашлык төягән машиналар ташкыны арта бара. Хәзер аларга Синдряков исемендәге, Муса Җәлил исемендәге, «Алга», «Заря» колхозлары, «Рассвет» совхозы игенчеләре дә кушылды. Сүз уңаеннан, элеватор быелгы сезон ашлыгын кабул итәргә әйбәт әзерләнде, игенчеләр өчен көнкүреш шартлары да тудырылды.

Ашлыкка юл ачык! Инде аның хәзер тигез ритм белән мөмкин кадәр тизрәк хәрәкәт итүен генә телисе килә.

**КЫРГА ҖЫР БЕЛӘН**

Район үзешчән сәнгать түгәрәгендә катнашучылар көче белән төзелгән агитбригада турында сүз бара. «Уңыш-91» колач җәйгән көннәрдә агитбригада членнары ашлык өчен көрәшүче кыр уңганнарын ял иттерергә хуҗалыкларга юнәлделәр. Маршрут «Алга», «Комбайн» колхозларыннан башланды. 5 кешедән торган агитбригада игенчеләр өчен тәмле телләрен, моңлы җырларын кызганмады. 4 нче мәктәп укытучысы Г. Таҗиев, шәфкать туташы Р. Нигъмәтуллинаның җырларын, Әлфия Таҗибаева биюен игенчеләр бик яратып кабул иттеләр. Концертта баян партиясен район культуры йорты директоры Р. Рәҗәпов алып барды ,Г. Алишева нәфис сүз белән чыкты.

Агитбригада икенче көнне XXI партсъезд исемендәге һәм «Татарстан» колхозларында булды. Алар белән бергә район үзәк аптекасыннан һәм парикмахерскаядан да иптәшләр игенчеләр янында булдылар, аларга кирәкле дарулар саттылар, көнкүреш хезмәте күрсәттеләр.

Ф. РӘШИТОВА.

## Гөрләп тора арыш басуы

«Большевик» колхозы игенчеләренең кәефе әллә ни начар күренми. Ни дисәң дә, яңа уңышны урып-җыю башланды. Күп көч түгеп үстергән аны игенче, күп өметләр баглаган. Тик нәтиҗә чамалы, шунысы үкенечле. Айга якын бер тамчы да яңгыр төшмичә, һаваның бик эссе торуы яңа уңышка зур зыян салды, билгеле. Шуңа да карамастан, 484 гектарда арыш һәм 150 гектар мәйданда борчак елына карата матур гына күтәрелгән.

Урак оешкан төстә көйле генә башланып китте. Бүгенге көнгә 275 гектарда арыш һәм борчакның 100 гектары теземнәргә салынган иде.

Олы юл буенда Ерепкино бригадасының арыш басуында туктыйбыз. Комбайнчылар бу кырда арышны теземнәргә салып бетереп киләләр. Алда Юрий Андреевич Евграфов комбайны арышны тигез теземнәргә салып бара. Монда ук без колхозның танылган комбайнчысы Федор Дмитриевич Еремеев белән бераз сөйләшеп тордык. Ул абыйсының малае Анатолий Петрович Еремеев белән арышны теземнәргә сала. Эшләренең сыйфаты әйбәт. Комбайннары көйләүле, югалтуларга юл куелмый. Алар икесе дә быелгы урак башыннан җитмеш берәр гектар мәйданда арыш урдырып, көнлек нормаларын күпкә арттырып эшлиләр.

Быелгы уракның үзенчәлекләре турында соравыма Федор Дмитриевич:

—1964 елдан бирле комбайнда эшләү дәверендә җиңел уракны күргәнем булмады диярлек, икмәк бер кайчан да, беркемгә дә җиңел бирелми инде ул. Менә арышны тизрәк җилләтеп, югалтусыз суктырып аласы иде,—ди ул, бер Анатолийга, бер комплекслы бригада бригадиры Геннадий Константинович Соловьевка карап.

Техниканы тын алышыннан сизгән тәҗрибәле механизатор янында эшләве Анатолийга рәхәт, әлбәттә. Шуңа да аның басу корабы алдан юл яра да. Егет яшь кенә булса да, шактый тәҗрибә туплап өлгергән. 8 классны тәмамлаганнан соң этисендә ярдәмче булып 3 ел эшләгән. Аннары хәрби хезмәттә дә техникадан аерылмый, шофер булып хезмәт итә. 1989 елдан солдат киемен салгач, этисе комбайнына үзе утыра. Ярдәмчесе Норлатның 99 нчы СПТУ укучысы Виталий Савгачев белән менә икенче урагы. Шунысын да әйтергә кирәк, былтыргы уракта колхоз механизаторлары арасында беренче урынны алганнар алар. Быел да сынатмаска исәпләре.

Геннадий Константинович безне тагын хуҗалыктагы булган бөтен техниканың докторы—эретеп-ябыштыручы Виктор Иванович Яковлев белән таныштырды. Җиңелчә гәүдәле, егетләрдәй җигез хәрәкәтле бу агай—механизатор егетләрнең иң якын ярдәмчесе дә. Кулыннан килмәгән эше юк. Тимерче дә ул, эретеп-ябыштыручы да, техниканы да биш бармагыдай белә. Һәм менә көне-төне механизатор егетләр белән үзе. Ә бит язгы чәчүдән соң Виктор Ивановичны лаеклы ялга озатканнар иде хезмәттәшләре. Түзәме соң ветеран йөрәге, тагын чыккан эшенә: «Кул-аяк йөргәндә, ничек ял итеп ятмак кирәк, вакыты андый түгел»,—ди ул гади генә.

Әйе, урак өсте бара, авыл эшчәннәре ил-көн алдында имтихан тоталар!

—Үзләреннән торган өлешен егетләр сынатмаслар, тик менә яңгырлар ешайды бу көннәрдә, ектырылган ашлык кибә алмый, ә озак яткырырга һич ярамый,—дип сүзгә кушыла колхозның баш агрономы Людвиг Викторович Казаков. «Үстерелгән кадәрен әрәм итмисе иде, һәр бөртеген, һәр уч саламны җыеп алу—көн бурычы».

Борчак басуында да комбайннар гөрелтесе. Аның соңгы гектарлары теземнәргә салына.

Монда Николай Кузнецов, Т-70 тракторында КС-2,1 чапкычы белән Виталий Яковлев, НУРБдан ярдәмгә кайткан Николай Васильев җиң сызганып хезмәт куялар.

Гомумән, хуҗалыкта механизаторлар җитәрлек, барлык техника урып-җыюга әзер, ватылырлык түгелләр. Озак та үтмәс—алар бер-бер артлы тезелешеп арыш, бодай, арпа, борчак басуларын иңләр. Шуңа күрә колхоз рәисе Валерий Федорович Булатовның күңеле тыныч. Егетләрнең уңганлыгына нык ышана ул. Әлегә йөзенә кызыллык китергәннәре юк.

Без дә большевиклыларга эшләрендә зур уңышлар телибез, үз бурычларын җиренә җиткереп башкаруларына һич шикләнмибез.

Р. ШӘЙХУЛЛИНА.

Г. РИЗАТДИНОВА.
«Комбайн» колхозы.

## Ремонт башланды

Хуҗалыкның товарлыклы-сөтчелек фермасында механик-терлекче Фаил Гафиятуллин җитәкчелегендәге звено кышкы чорга күчәр алдыннан биналарны ремонтлау эшләрен башлап җибәрде.

Звено бүгенге көнгә тирес түгү транспортерларын алыштыра, читлекләрне, улакларны төзәтә.

Г. РИЗАТДИНОВА.
«Комбайн» колхозы.

# Иң мөһиме—гадел бәя

**Күптән түгел Норлат разведка бораулавы идарәсе үзенең ярты еллык хезмәтенә йомгак ясады.**

Хезмәт коллективы конференциясе идарә начальнигы Ю. Г. МӨХӘРМӘТОВның «Ярты еллык эш йомгаклары һәм елның икенче яртысында идарә алдында торган бурычлар» дигән доклады белән башланып китте.

«Идарә эзләнү-тикшерү эшләрен элекке мәйданнарда дәвам итте. Төп хезмәт күрсәткече—ягъни запасларны үстерү планы арттырып үтәлде.

Заказчыларга план буенча каралган 11 скважина урынына 12 разведка скважинасы тапшырылды»,—дип белдерде докладчы. Файдалануга тапшырылган скважиналар саны да пландагыдан 1гә артык. Ә ягулык промышленносте өчен пландагы 5 урынына 4 скважина тапшырылган. Ярты елда «Татнефть» берләшмәсе өчен бораулаган катлам пландагыдан 8095 метрга артык. Ә разведка өчен бораулау планы 89,5 процентка гына үтәлгән. Эксплуатацион бораулау планы 10366 метрга арттырып үтәлә, ә «Татнефтепром» берләшмәсе өчен бораулау планда 9000 метр каралган булса, чынлыкта 5372 метр гына бораулаңган. Докладчы әйтүенчә, бер бораулау бригадасына туры килгән эш күләме пландагыдан арттырып үтәлүгә карамастан, узган елның шушы чорындагы нәтиҗәдән түбәнрәк тора икән. «Беренче ярты еллык планны биш бораулау бригадасы үти алмады,—дип белдерде Юнир Гобәйдуллович. —Болар—Газизов—Самойлов, Газизов—Фролов, Имуков—Рәхмәтуллин, Әхмәтов — Шәмсетдинов, Еромасов—Галдин бригадалары. План үтәлмәүнең төп сәбәпләре булып эш дәвамында катлауланулар аркасында һәм бер скважинадан икенчесенә күчкәндә вакытны күп югалту тора.

Эксплуатацион бораулау бригадалары арасында иң яхшы күрсәткеч—Хәсәншин—Мостафин бригадасында. Алар планда каралган 10600 метр урынына 13265 метр тирәнлегендә катлам борауладылар. Моннан тыш, докладчы Фомин—Матюшкин һәм Захаров—Нечаев бригадаларының да яхшы эшләүләрен билгеләп үтте, һәр бригаданың эш үзенчәлекләренә тукталып бәя бирде. Докладчы катлам бораулавында брак булу һәм авария куркынычы туу очраклары хакында да сүз алып барды.

Отчет чорында скважиналар бораулауда 1 брак очрагы булган. «Моңа бораулаучының игътибарсызлыгы сәбәпче,—дип белдерде иптәш Мөхәрмәтов.— Моннан тыш, берничә тапкыр авария булу куркынычы да туды. Хәлне тиз вакыт эчендә төзәттек, шуңа күрә ул эш балансында чагылыш тапмады. Әмма моның бик начар нәтиҗәләргә китерүе мөмкин иде. Шуңа күрә бүгенге көндә ул хакта сүз кузгатмый гына узып китү дөрес түгел. Мәсәлән, шушы вакыт дәвамында 6 скважинада инструмент эләгеп калу, 2 скважинага чит әйберләр төшерү, 5 скважинада бораy сыну очраклары күзәтелде. Сәбәбе нәрсә дисезме—бораулау бригадасында дисциплинаның йомшаруы, эшне башкаручыга таләпнең түбәнәюе, скважиналарның үткәрүчәнлегенә контроль кимү нәтиҗәсе ул,—диде докладчы. —Моннан котылу юлы бер генә: контроль һәм таләпне көчәйтү белән бергә, яшь мастерларның һәм инженер-техник хезмәткәрләрнең профессиональ хәзерлек дәрәҗәсен күтәрү, аларны алдынгы технология һәм тәҗрибә белән эшләүгә тарту. Эш башкаручыларны хезмәт урыннарында өйрәтеп осталыкларын арттырырга кирәк.

Алты ай дәвамында коллектив тарафыннан 23 рационализаторлык тәкъдиме кертелде, шуның 17 се гамәлгә алынды һәм аларның экономик нәтиҗәсе 207 мең сум тәшкил итте. Ә план буенча бу тармактан елына 150 мең сум файда алу каралган иде.

Хезмәт нәтиҗәләре күрсәткеч булганда да, һәр җыелышта, киңәшмәдә сөйләнә торган бер «авырткан» җиребез бар. Сәбәпсез эшкә чыкмый калучылар һәм җәмәгать тәртибен бозучылар санының кимүе сизелми. Ә нигә алар үзгәрергә дә уйламыйлар һәм нигә һаман да коллектив члены булып кала бирәләр? Бу нилектән шулай соң? Сәбәпләре берничә, әлбәттә. Беренчедән, цех җитәкчеләре, мастер һәм прораблар үз кул астында эшләүчеләргә карата иң гадәти таләпчәнлекне дә күрсәтмиләр, эчке тәртипне саклау, вазифаны төгәл һәм сыйфатлы итеп башкару зарурилыгы соралмый.

Икенчедән, шул ук җитәкчеләр кешеләрне һәрвакытта да эш белән тәэмин итеп бетермиләр, өстәп язу белән шөгыльләнәләр.

Өченчедән, күп кенә очракларда эчүчеләргә, хезмәт һәм җәмәгать тәртибен бозучыларга карата либераллык күрсәтәбез. 6 айда 22 кешенең сәбәпсез эшкә чыкмавы шушы йомшаклык нәтиҗәсе ләбаса ул. Ә шуларның 4 се генә эштән читләтелгән. Калганнары арасында хәтта дисциплинар җәза да алмаганнары никадәр! Цех җитәкчеләренең әлеге прогулчыларны администрациядән яшереп калу очраклары да ачыкланды.

Хезмәт һәм җәмәгать тәртибен бозучыларның намуслы эшләүчеләр белән беррәттән барлык мөмкинлекләрдән файдаланып яшәве һич тә дөрес мөнәсәбәт түгел!»—дип бәяләде докладчы.

Аннан соң коллектив эше һәм тормышы турында сөйләшүне профком рәисе Г. Ш. СӨЛӘЙМАНОВ дәвам итте. Ул үзенең чыгышында 1991 елгы коллектив килешүнең үтәлеше барышына тукталды.

Шуннан соң конференциядә катнашучылар фикер алышуларга күчтеләр. РИТС-2 начальнигы В. П. Смородин эш киемнәре, химик реагентлар җитмәүдән зарланды. Скважиналарны беркетү цехы мотористы Ф. Х. ИСХАКОВ көнкүреш шартларын уңайландыру кирәклеген искәртте. Скважиналарны үзләштерү цехы начальнигы урынбасары Ф. И. ГАЛИМОВ: «Узган алты айда төп үзләштерү эшеннән бигрәк күбрәк ремонт белән шөгыльләнергә туры килде. Үзләштерү циклы зурайды»,—дип белдерде һәм моннан котылу юлы булырак разведка скважиналарының технологиясен яхшыртырга кирәк дигән тәкъдим белән чыкты. Яңа техниканы файдалануга кертү, экология мәсьәләләре дә аның чыгышында киң урын тапты. Прокатлау-ремонтлау цехы начальнигы М. Я. ВОЛГАЙ бораулау җиһазлары, материаллар җитмәвен искәртте. «Инде кыш—борын төбендә! Ә Южный поселогы һаман сусыз! 150 метр озынлыкта торба суза алмыйбыз, чөнки безгә трассаны бирмиләр. Нәтиҗәдә өчәр этажлы йортлар сусыз утыра!»—дип борчылу белдерде. Техника куркынычсызлыгы буенча баш инженер Ф. М. ЧЕРКАСОВ шулай ук үзен борчыган мәсьәләләр белән уртаклашты.

Конференциядә халык депутатларының район Советы башкарма комитеты рәисе В. В. БОГАТИКОВ катнашты һәм чыгыш ясады. Ул үзенең чыгышында районның бүгенге көндәге экономик хәлен бәяләде һәм алда торган бурычлар хакында сүз алып барды.

Монда шулай ук «Татнефть» берләшмәсенең генераль директоры урынбасары Р. Х. ФӘТКУЛЛИН да катнашты һәм чыгыш ясады.

Соңыннан конференциядә күтәрелгән мәсьәләләр буенча хезмәт коллективы карар кабул итте.

Шунда ук коллективның өлкән эшчесе, тракторчы Р. С. ШӘРӘФЕТДИНОВны 60 яше тулу уңае белән котлаулар булды.

Шунысы сөенечле, конференциядә хезмәт коллективының тормышына, кимчелекләргә күз йоммыйча, һәр яктан гадел бәя бирелде.

**К. ҖАМАЛЕТДИНОВА.**



**«Заветы Ильича» колхозының товарлыклы-дуңгызчылык фермасында Елизавета Сергеевна Тришина ике дистә елдан артык дуңгыз караучы булып эшли. Ул тырышлыгы аркасында үз карамагындагы дуңгызлардан 325 әр грамм уртача тәүлеклек үсеш алуга ирешә.**

**Фермада Елизавета Сергеевнаның ире Геннадий Федорович та эшли. Ул да мактаулы терлекче.**

**Уллары Евгений белән Владимир да бәхет эзләп читкә китмәде, ата-аналары янында калдылар. Берсе ветеринар врач, икенчесе—терлекче.**

**Тришиннар әнә шулай бергәләп хезмәт куялар һәм эштән соң табын янында шатлык-кайгыларын уртаклашалар.**

**Рәсемдә: дуңгыз караучы Е. С. Тришина.**

**В. Никонорова фотосы.**

**КИСКЕН СИГНАЛ**

# Сыйфат начар

Икмәк турында күпме җырлар языла, күпме матур сүзләр сөйләнә, икмәкнең тәме сабый чактан ана сөте белән безнең каныбызга, җаныбызга сеңә. Икмәк—һәркем өчен изге нәрсә. Әмма ничек кенә булмасын, Кизләү икмәк пекарнясында пешерелгән ипи авызга алгысыз. «Пешкән ипине терлеккә ашатабыз!»—дип үзебезне үзебез гаеплибез, ләбаса. Ә менә бу ипине кайвакыт хайван да ашамый. Ипигә бәя күтәрелә дигәч аның сыйфаты да яхшыра төшмәсме дип өметләнгән идек. Элек иске бәя вакытында бер ипинең 34 тиен торганлыгын кыйммәтсенә идек, ә хәзер 52 яки 68 тиенлеген казларга ашату өчен алабыз. Чөнки аның йә камыры яхшылап болгатылмаган, йә ныграк әчегән, йә тозы күп салынган, йә бөтенләй салынмаган була. Һич югы он һәм тоз төерләре булса да чыга. Бөтен ипи эченнән өзек җепләр дә килеп чыккалый. Бервакыт, хәтта тиен акчалар да таптык. Анысында инде, бәлки ипи пешерүчеләр үзләренең начар сыйфатлы продукциясе өчен безнең чыгымнарның бер өлешен түләргә уйлаганнардыр дип юандык. Чөнки ипинең йомшак өлешен эвәләп әллә нинди сыннар ясарга мөмкин. Бераз осталык кына кирәк.

Бәлки безгә бу ипине алудан бөтенләй баш тартыргадыр? Ләкин бөтен эш бер нәрсәгә барып терәлә: бу икмәк пешерүчеләрнең көндәшләре юк. Ә безнең—Кизләүдә һәм тирә-күрше авылларда яшәүчеләрнең ипине сатып алмыйча чарабыз юк. Без барыбыз да ипине өйдә пешерергә күнгән халык. Әмма язын һәм җәен вакыт җитми: бөтен халык кырда һәм бакчада. Он белән дә өзеклекләр килеп чыккалап тора. Шуңа күрә, әгәр район үзәгенә очраклы гына юлыбыз төшә калса да, без беренче чиратта ипи сатып алуны кайгыртабыз. Ни генә дисәгез дә, Норлатта икмәкне бик тәмле итеп, ундырып пешерәләр. Югыйсә, оны да шул, тозы да. Ләкин Норлат икмәген ашаганнан соң эчең дә, башың да авыртмый. Анысы хак.

Бәлки Норлат уңганнары безнең булдыксызларны да ипи пешерү серләренә өйрәтерләр? Гафу итегез шулай дигәнгә. Әмма изгеләрдән дә изге икмәкне шулай мәсхәрә итүчеләрне кем дип атарга соң? Иртәгә табыннарда чын мәгънәсендәге икмәк булсын өчен безгә нишләргә микән?

**Кизләү авылы кешеләре исеменнән К. ИЗМАЙЛОВА.**

# Ишеттегезме әле...

**ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ ТӨЗЕЛДЕ**

Демократик реформалар хәрәкәтен төзүчеләр җыелышы хәрәкәтнең беренче съездын әзерләү буенча оештыру комитеты төзеде. Аның рәисе итеп Эдуард Шеварднадзе сайланды. Съезд шушы елның сентябрендә үткәрелер дип уйланыла. Ярдәмче рәисләр итеп Аркадий Вольский, Иван Лаптев, Александр Яковлев сайланды.

**КИРӘКЛӘРЕ КАЛМАДЫ**

Ленинград мэры Анатолий Собчак Югары Советны һәм СССР халык депутатлары съездын тиз арада тарату кампаниясен башлап җибәрү инициативасы белән чыкты. Бу моны әлеге органнар «үтә реакционга әйләнү» белән аңлата.

**БӘЙСЕЗЛЕК КӨНЕ**

Үткән елны 16 июльдә Украина суверенитеты турында Декларация игълан ителгән иде. УССР Югары Советы бу көнне бәйрәм көн дип санарга карар итте. Быел Бәйсезлек көне ял көннәренә туры килде. Шуңа күрә Украина өч көн—14 июльдән алып 16 июльгә кадәр—ял итте.

**ИСЕМНӘР ОНЫТЫЛМЫЙ**

Шәрәф Рәшидов исемен хәзер Җизак районындагы бер колхоз урамы йөртәчәк. Үзбәкстан Компартиясе Үзәк Комитетының элекке беренче секретаре исеме тагын ефәк эрләү фабрикасына бирелде.

**ЧАКЫРЫЛГАН КУНАК**

АКШтан, Австриядән, Германиядән, Төркиядән һәм Финляндиядән татар җәмгыятьләре вәкилләре Бөтендөнья татар лигасының оештыру съездын үткәрү өчен җыелдылар. Яңа халыкара оешманың Президенты итеп Мюнхенда яшәүче, Европа татар-башкорт милли хәрәкәтенең башлыгы 74 яшьлек Али Акыш әфәнде сайланды.

Соңгы вакытка кадәр доктор Акыш безгә бары тик «Советка каршы» язмалары буенча гына мәгълүм иде.

Без яңаручы Татарстанга үз-үзенә йомылу да, яңа Карабах та янамавын күрдек, дип раслый доктор Акыш. Шуңа күрә күп яклы нәтиҗәле элемтәләр оештыру өчен кулдан килгәнне эшләрбез.

